**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# 2020 елда медицина оешмасын мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрына кертү турында хәбәрнамә бирү вакытын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы $2^1$ өлеше нигезендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә йогышлы яңа коронавирус чире таралу куркынычы белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Йогышлы яңа коронавирус чире белән авыруына шик туган очракта яки расланган диагноз булганда пациентларга медицина ярдәме күрсәтүче, пациентларны хастаханәләргә озатуның Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган маршрутына кертелгән медицина оешмалары өчен 2020 елда медицина оешмасын Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминиятләштерүгә өлкәсендә эшчәнлек алып баручы медицина оешмалары реестрына кертү турында хәбәрнамә бирү вакытын 2020 елның 1 июленә кадәр дип билгеләргә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 10 июнь
№ ПУ-342